ГЛАВА БЕРЕЗКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422712, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с.Березка, ул.Новостройка, 15А

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАЕНЛЫК АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
422712, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Каенлык авылы, Новостройка ур, 15А

Тел./факс: +7(84365) 79-2-08, e-mail: Berez.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**22 ноябрь, 2021 ел** **№ 1**

## Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең Соловцово, Каенлык, Мамонино, Тимофеевка, Өнсә торак пунктларында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге Уставының 22 статьясы һәм 2019 елның 22 октябрендәге 22 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә:

1.1. 2021 елның 3 декабрендә 11.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең Соловцово торак пунктында түбәндәге адрес буенча: Соловцово ав., Шоссейная ур., (тукталыш янында);

1.2. 2021 елның 3 декабрендә 12.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең Тимофеевка торак пунктында түбәндәге адрес буенча: Тимофеевка ав., Яшел ур., (5 йорт янында).

1.3. 2021 елның 3 декабрендә 15.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең Каенлык торак пунктында түбәндәге адрес буенча: Каенлык ав., Үзәк ур., (мәдәният йорты янында).

1.4. 2021 елның 3 декабрендә 16.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең Мамонино торак пунктында түбәндәге адрес буенча: Мамонино ав., Гвардейская ур., (кибет янында).

1.5. 2021 елның 3 декабрендә 17.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең Өнсә торак пунктында түбәндәге адрес буенча: Өнсә ав., Үзәк ур., (мәдәният йорты янында).

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

2.1. Соловцово торак пунктында: «2022 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең Соловцово торак пункты территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга:

- Соловцово торак пунктында урам яктыртуы челтәрләрен ремонтлау
- вак таш сатып алу һәм Соловцово торак пунктында посёлок эчендәге юлларны ремонтлауга

юллау белән килешәсезме?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

2.2. Тимофеевка торак пунктында: «2022 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең Толмач торак пункты территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 2000 (ике мең) сум күләмендә үзара салым кертергә, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга:

- Тимофеевка торак пунктында зиратны коймалау өчен төзелеш материаллары сатып алу

юллау белән килешәсезме?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

2.3. Каенлык торак пунктында: «2022 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең Каенлык торак пункты территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга:

- Каенлык торак пунктында урам яктыртуы челтәрләрен ремонтлау;
- Каенлык торак пунктында Бөек Ватан сугышында һәлак булган катнашучыларга Стелла урнаштыру

юллау белән килешәсезме?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

2.4. Мамонино торак пунктында: «2022 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең Мамонино торак пункты территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга:

- Мамонино торак пунктынын зиратына вак таш сатып алу
- Мамонино торак пунктында урам яктыртуы челтәрләрен ремонтлау

юллау белән килешәсезме?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

2.5. Өнсә торак пунктында: «2022 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең Өнсә торак пункты территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга:

- Өнсә торак пунктында Бөек Ватан сугышында һәлак булган катнашучыларга Стелла урнаштыру

- Өнсә торак пунктында җәяүлеләр күпере урнаштыру

юллау белән килешәсезме?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм җирлекнең рәсми сайтында кабул ителгән көненнән алып 10 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Каенлык авыл җирлегенен
башлык урынбасары В.В.Виногорадов